# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ, март, 2026 ел № 15

*Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

## *Газетаның сәхифәләре:*

*1. Бакчабызда эвакуация чарасы уздырылды.*
*2. Бездә бүген кунак бар.*
*3. 8 март белән, әниләребез!*
*4. Тәрәз төбендә яшеллек.*
*5. Нәүрүз бәйрәме мөбәрәк булсын!*

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Р.Г.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
**Хөсәенова В.В.**

## Бакчабызда эвакуация чаралары уздырдык.

Без бакчабызда тәрбияләнүчеләр белән эвакуация чаралары уздырдык. Чараларны системалаштыру нәтиҗәсендә балаларда куркынычсызлык кагыйдәләрен белү һәм төрле гадәттән тыш хәлләр нигезендә үз-үзеңне тотышыңны көйли белү нигезе формалаша. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре белән дә «учреждение хезмәткәрләренең гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләре», «беренче медицина ярдәме күрсәтү»дигән инструктаж үткәрелде.










**Балаларның тормышын һәм сәламәтлеген кайгырту балалар бакчасының һәм әти-әниләрнең иң мөһим бурычларының берсе.**

Безнең балалар бакчасында бу айда «Основы безопасности  жизнедеятельности» исеме астында, Бөтенроссия күләмендә уздырылган акциядә катнашты. Шул уңайдан безгә кунакка янгын сүндерү часте хезмәткәре Саттаров Ленар Габделхай улы килде. Ул безнең кечкенәләр төркеменә йөрүче Азаматның әтисе дә әле.

Белемнәрне ныгыту максатыннан балалар белән янгын вакытында үз - үзеңне тоту кагыйдәләре дигән темага әңгәмә уздырдык.







**Яз белән бергә матур бәйрәм 8 Март - халыкара хатын-кызлар көне килә**.

Безнең балалар бакчасы өчен бу иң яраткан бәйрәм. Чөнки әлеге бәйрәмдә безнең балаларыбызның яраткан әниләре, әбиләре катнаша.

Бәйрәмдә күңелле атмосфера хөкемсөрде, бик күңелле һәм кызыклы булды. Балалар шигырьләр сөйләделәр, әниләр һәм әбиләр турында дулкынландыргыч җырлар җырладылар һәм төрле уеннар уйнадылар. Алай гына да түгел, әиләре белән төре кызыклы ярышларда, эстафеталарда катнаштылар. Әниләре өчен балалар үз куллары белән ясалган бүләкләр – искиткеч открыткалар әзерләделәр. Аларда күңел җылысы һәм мәхәббәт хисләре салынган иде. Бәйрәм, һичшиксез, балалар бакчасы тормышына язгы шатлык һәм бәхет атмосферасы алып килде.








# Тәрәз төбендә яшеллек

Балалар бакчасына йөрүче балалар белән суган утырттык. Балалар бу эшне  бик теләп һәм кызыксынып  башкардылар. Тәҗрибәнең төп максаты булып, балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү, суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү, суган үстерү турындагы белемнәрен тулыландыру иде. Беренче балалар белән түтәлдә һәм тартмада үскән суган рәсемнәрен карадык. Шуннан соң инде балалар белән бергә савытка балчык салып суганнар утырттык, су сиптек. Балаларга суган утырту бик ошады. Алга таба суганның үсешен күзәтү тагын да кызык булачак. Шулай итеп, без балаларны кечкенәдән бакчачылык серләренә өйрәтәбез.









**Безнең балалар бакчасында язның тагын бер матур бәйрәме - Нәүрүз бәйрәме узды.**

Нәүрүз - яз бәйрәме, яхшылык бәйрәме.

Фарсы теленнән тәрҗемә иткәндә «яңа көн» дигән сүз.

Бу көнне балалар белән бергәләп Кыш бабайны озаттык, Язны - Нәүрүзбикәне каршыладык. Татар халык уеннары уйнадык, шигырьләр сөйләдек, җырлар җырладык. Балалар белән мәкальләр, сынамышлар, табышмаклар әйтештек.

Бәйрәмебез күңелле узды.










